| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2025 Кукмара ш. № 661

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2010 елның 05 маендагы 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2010 елның 05 маендагы 35 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.4 пунктының 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлеше нигезендә яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә, прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарынааны коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында, Башкарма комитетның башка муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан коррупциячел хокук бозулар кылу, белешмәләр тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү йә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр

бирү фактлары хакында хәбәр иткән Башкарма комитет хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында була.»

2. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**